# КАРАР

## Татарстан РеспубликасыЗәймуниципаль районы Югары Шепкә авыл жирлеге составына керүче Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 2

05.12.2021

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 05 нче декаберендә булып узган гражданнар жыены нәтижәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:«Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге жирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- коены ремонтлау.

Гражданнар жыены нәтижәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 16 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны14 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтижәләре буенча халык жыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 14 жыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 жыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык жыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар жыенын узган дип танырга, халык жыены нәтижәләрен дөрес дип санарга.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкәавыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәүавылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге жирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

-- коены ремонтлау соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында»

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Югары Шепкә
авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.